ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26. 03. 2019 г.Мензелинск № 332

Минзәлә муниципаль районы территорияләрен санитар чистарту буенча икеайлык игълан ителү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.03.2019 елдагы №567-р карарын тормышка ашыру максатларында, Минзәлә муниципаль районы территориясендә санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны санитар-эпидемиологик һәм халыкның экологик куркынычсызлыгына җавап бирүче хәлгә китерү өчен

КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Минзәлә муниципаль районы территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык (алга таба – икеайлык) игълан итәргә.
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә санитар-экологик икеайлык уздыруга җаваплы итеп Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дмитрий Александрович Чухланцевны билгеләргә.
3. Ведомство карамагындагы территорияләрне санитар чистарту буенча планны Кушымта №1 нигезендә эшкәртергә һәм расларга.
4. “Мехуборка НК” ҖЧҖгә Минзәлә шәһәре территорияләреннән һәм Минзәлә муниципаль районы авыл җирлекләреннән чүп җыюны һәм каты көнкүреш калдыклары полигонына чыгару буенча махсус техниканың нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә, каты көнкүреш һәм биологик калдыклар полигоннарын эксплуатацияләү һәм тиешенчә карап тотуны тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
5. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Р.Г.Таймасовка терлек калдыкларын җыю һәм куркынычсыз утильләштерү буенча авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр белән эшне оештыруны тәкъдим итәргә.
6. ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе начальнигы Н.Г.Гариповка, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсенә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтнең ТР буенча Яр Чаллы, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарында территораль бүлек (Яр Чаллы территориаль бүлеге) начальнигы урынбасары М.В.Гирфановка, Россия ЭЭМнең Минзәлә муниципаль районы буенча бүлек начальнигы И.М.Хаҗиевка, “Минзәлә район дәүләт ветеринария

15. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районы бакшарам комитеты җитәкчесе урынбасары Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Җитәкче К.Р.Нәҗмиев

берләшмәсе” ДБУ начальнигы А.И.Гафуровка, “Татарстан Республикасы буенча Федераль янгын хезмәтенең 15 нче отряды” ФДКУнең 122 нче янгын часте начальнигы Р.В.Комаровка, “Минзәлә урманчылыгы” ДКУ җитәкчесе А.Х.Гайфуллинга табигатьне саклау, санитар-эпидемиологик, ветеринар, янгынга каршы законнарның таләпләрен үтәү буенча күзәтчелекне көчәйтергә.

7. Оператив штабка шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә, автомобиль юлларының яр буе полосаларында, авыл хуҗалыгы карамагындагы объектларда, пляжларда, скверларда, паркларда, балалар мәйданчыкларында, азык-төлек һәм кием-салым базарларында, халыкның күпләп ял итү урыннарында, бакчачылык җәмгыятьләрендә, гараж кооперативларында, шәхси секторда җитештерү һәм куллану калдыкларын санкцияләнмәгән урнаштыруны булдырмауны тәэмин итәргә.

8. ТР КоАПның 3.6 маддәсе буенча ТРның Минзәлә муниципаль район территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә тиешле вәкаләтле вазифаи затларга Минзәлә муниципаль районының авыл җирлекләрен һәм Минзәлә шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгәнчә үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтү өлешендә эшне активлаштырырга, территорияләрнең санитар торышына контроль һәм күзәтүне системалы рәвештә уздырырга.

9. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясенә эшне активлаштырырга.

10. Минзәлә муниципаль районы оешмаларына һәм җирлек башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә: җир законнары нигезендә бирелгән җир участоклары территорияләрендә санитар җыештыруны тәэмин итү, икеайлык уздыру һәм оештыру турында отчетларны оператив штабка тапшырырга.

11. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Минзәлә Шәһәре” ТОС җитәкчеләренә булачак икеайлык турында халык арасында аңлату эшләре алып барырга, һәр торак подъездны күрсәтмә агитация белән тәэмин итәргә, хосусыйлыгында торак йортлар һәм хуҗалык корылмалары булган халыкны янәшәдәге территорияләрне чистарту һәм төзекләндерү буенча эшкә җәлеп итәргә, халык арасында өмәләр уздырырга, икеайлык әзерләгәндә һәм уздырганда актив катнашуны тәкъдим итәргә.

12. Иҗтимагый яшьләр (волонтерлык) оешмаларын ведомствога караган территорияләрне санитар-экологик чистарту буенча эшкә ирекле нигездә җәлеп итәргә.

13. “ТАТМЕДИА” АҖнең “Минзәлә” Мәгълүмати-мөхәррият үзәге филиалына газета битләрендә санитар-экологик хәлне яхшырту буенча даими яктыртуны тәэмин итәргә.

14. Минзәлә муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетларының җитәкчеләренә авыл җирлекләре территорияләрен чистарту буенча карар чыгарырга һәм җирлек территорияләрен санитар чистарту буенча чаралар планын эшләргә, башкарылган эш турында оператив штабка мәгълүмат тапшыруны тәкъдим итәргә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | көн саен бер сәгать эчендә | җитәкчеләре, ТОС җитәкчеләре, оператив штаб |
| 6. | “Агач утырт” акциясен уздыруны оештыру. | 5 май 2019 ел. | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУ, ТОС җитәкчеләре, оператив штаб |
| 7. | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә исәптә торучы гражданнарның санитар чистарту, төзекләндерү һәм шәһәрне яшелләндерү буенча санитар чистартуда актив катнашуларын тәэмин итәргә. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | “Минзәлә муниципаль районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДБУ, “Чиста шәһәр “ МУП |
| 8. | Бина фасадларын һәм цокольләрен ремонтлау буенча чаралар оештырырга, барлык төр коймаларга ревизия ясарга, ремонтларга һәм буярга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Идарәче компания» ҖЧҖ, «Чиста шәһәр» МУП, төрле хосусыйлыкта булган оешма җитәкчеләре, бина хуҗалары. |
| 9. | Территорияләрне санитар чистарту буенча механизацияләнгән бригадалар булдырырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП, «Идарәче компания» ҖЧҖ |
| 10. | Калдыкларны урнаштыруның санкцияләнмәгән урыннарын ачыкларга һәм ликвидацияләргә. | Көн саен 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, Экология һәм табигый ресурсларны саклау министрылыгының Кама буе территориаль идарәсенең мобиль төркеме, авыл җирлекләре башлыклары, ТОС җитәкчеләре, оператив штаб. |
| 11. | Яшелләндерү буенча эшне оештырырга: үсентеләр утыртырга, клумбалар ясарга, агачларны кисәргә, карт һәм корыган агачларны кисәргә һәм күчерергә. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, “Минзәлә урманчылыгы” ДБУ, төрле хосусыйлыкта булган оешма җитәкчеләре, оператив штаб. |
| 12. | Юл буе полосаларын чистартырга (федераль трасса, төбәк трассалары, район юллары) | | «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалы, «Чиста шәһәр» МУП |

Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Карары белән расланган
Кушымта № 2

№_______ дата __________2019 ел

Минзәлә муниципаль районында
территорияләрне санитар чистарту, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча чаралар
ПЛАНЫ

| № пп | Чаралар атамалары | Башкару сроклары | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | ТРның Минзәлә муниципаль районында тышкы төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау Кагыйдәләре таләпләре нигезендә төрле хосусыйлыкта булган оешма җитәкчеләрен һәм гражданнарны беркетелгән һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм санитар тәртиптә тоту буенча эшләрне башкарырга җәлеп итәргә. | 01.04.- 31.05.2019 ел. | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, оператив штаб, авыл җирлекләре башлыклары. |
| 2. | Шәһәр территорияләрен санитар чистарту, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча икеайлыкта катнашуга җәлеп итү өчен халык арасында оештыру, аңлату эшләрен уздырырга. | 01.04. - 31.05.2019 ел. | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары, «Идарәче компания» ҖЧҖ, “Минзәлә” газетасы редакциясе, ТОС җитәкчеләре, оператив штаб |
| 3. | “Чисталык дәресе”, “Бөтендөнья җир көне” экологик белем бирү акцияләре уздыруны оештырырга һ.б.лар. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Мәгариф бүлеге» МКУ, уку йортлары җитәкчеләре, «Будет Чисто» яшьләр экологик хәрәкәте |
| 4. | Шәһәр территорияләрен һәм авыл җирлекләре территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча өмәләр оештырырга. | 7, 14, 21, 26, апрель, 5, 19 май 2019 ел. | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары, төрле хосусыйлыкта булган оешма җитәкчеләре, ТОС җитәкчеләре, оператив штаб |
| 5, | Җир участокларын һәм алар янәшәсендәге территорияләрне көн аен җыештыру һәм атна саен санитар көннәр уздыруны оештырырга. | Һәр атнаның җомга көннәрендә: | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары, төрле хосусыйлыкта булган оешма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Урам атамаларынының һәм йортларның нумерациясен, юл билгеләре аншлагларын яңарту буенча эшне оештырырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Идарәче компания» ҖЧҖ, “Чиста шәһәр” МУП, авыл җирлекләре башлыклары |
| 14. | Тукталыш павильоннарын чистарту, ремонтлау буенча эшне оештырырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары |
| 15. | Юллардагы чокырларга ремонт ясарга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП |
| 16. | Контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау буенча эшләрне оештырырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП |
| 17. | Гражданнарның ял итү урыннарын чистарту һәм төзекләндерү, шәһәр һәм авыл җирлекләре урамнарында эскәмияләрне ремонтларга һәм буярга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, ТОС җитәкчеләре, ПМК «Мелиорация» |
| 18. | Буаларны, күлләрне, шәһәр пляжларын чистарту һәм төзекләндерергә. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, |
| 19. | Канализация челтәрләрен төзергә һәм ремонтларга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» ААҖ |
| 20. | Су агу торбаларын һәм канауларны чистартартырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП |
| 21. | Шәһәр һәм район чишмәләрен чистартырга һәм төзекләндерергә. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, ТОС җитәкчеләре |
| 22. | Автоюллар буйлап һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре урамнары буйлап агачларны агартырга, бордюр ташларын, яктырту баганаларын агартырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, Түбән Кама электр челтәрләре” “Челтәрләр компаниясе” ААҖ филиалы |
| 23. | Каты көнкүреш калдыклары полигонын эксплуатацияләү һәм тиешенчә карап торуны тәэмин итәргә, икеайлык чорында каты көнкүреш калдыклары полигонына халыктан бушлай чүп кабул итүне оештырырга. | Көн саен | «Чиста шәһәр» МУП |
| 24. | Урамнарны, йорт яны территорияләрен тышкы яктыртуга ревизия уздырырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Идарәче компания” ҖЧҖ, «Чиста шәһәр» МУП |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 25. | Зиратларны һәм аның янәшәсендәге территорияләрне чистартырга. | 01.04. – 31.05.2019 ел. | «Чиста шәһәр» МУП, авыл җирлекләре башлыклары, ШЭ Титов.А.Н., ТОС җитәкчеләре |
| 26. | Йорт яны территорияләрен җыештыруны оештырырга | Көн саен | «Идарәче компания» ҖЧҖ, авыл җирлекләре башлыклары, ТОС җитәкчеләре |
| 27. | Каты көнкүреш калдыклары полигонына шәһәр территориясеннән чүп җыю һәм чыгару буенча махсус техниканың нәтиҗәле эшен оештырырга. | Көн саен 01.04. – 31.05.2019 г. | «Чиста шәһәр» МУП |
| 28. | Терлекчелек комплекслары калдыкларын санкцияләнмәгән урнаштыру урыннарын ликвидацияләү буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр белән эшне оештырырга. | 01.04. – 31.05.2019 г. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсе начальнигы Таймасов Р.Г. |
| 29. | Административ комиссиянең һәм вәкаләтле затларның вазифаи затларның эшен активлаштырырга, Минзәлә муниципаль район территориясендә админстратив хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә. | Көн саен 01.04. – 31.05.2019 г. | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Нәҗмиев К.Р. |
| 30. | Икеайлык уздыру буенча эшне координацияләү өчен оператив штаб утырышларын уздырырга. | Атна саен 01.04. – 31.05.2019 г. | Икеайлык уздыру буенча эшне координацияләү өчен оператив штаб рәисе |